МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ ____656/о____

П Р И К А З                                                  Б О Е Р Ы К

«__27__»_______11_______2024

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган мәгълүматларны бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 28 декаб-рендәге 215/о номерлы боерыгына үзгәреш кертү хакында

«Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 7 октябрендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган мәгълүматларны бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 28 декаб-рендәге 215/о номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның 12 августындагы 278/о номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәреше белән) үзгәреш кертеп, 4 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге боерыкның Татарстан Республикасының «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенә карата 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган нигезләмә-ләреннән тыш, әлеге боерыкның гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына карата 2027 елның 1 гыйнварыннан кулланыла.».

2. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин

итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына (Р.Җ.Зәйнуллинага) әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр М.М.Айзатуллин

Отдел контроля исполнения документов